КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 52

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен, шул исәптән балалар өчен, интернат йортларның исемен үзгәртү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының психик тайпылышлары булган гражданнар өчен, шул исәптән балалар өчен, интернат йортларның исемен үзгәртү тәкъдимен кабул итәргә:

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Алабуга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Зеленодольск интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Зеленодольск социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Казан социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Кама Аланы социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Яңа Чүриле социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Чистай социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Югары Утар балалар йорты интернаты» дәүләт казна учреждениесен «Югары Утар балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесенә;

«Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Дербышка балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесен «Дербышка балаларга социаль хезмәт күрсәтү йорты» дәүләт казна учреждениесенә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына календарь көннәрдә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре уставларына тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Психоневрологик интернатларның исемен үзгәртү турында» 2021 ел, 31 май, 394 нче;

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының исемен үзгәртү турында» 2021 ел, 06 сентябрь, 834 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының исемен үзгәртү турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 834 нче карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2023 ел, 30 март, 375 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин